| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**2017 елның 30 гыйнваре** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 138** |
|---|---|---|

2017 елның I кварталына салым салынырга тиешле гражданнар керменең һәм мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән, Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләмен билгеләү методикасына, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының«Россия Федерациясе субъектлары буенча 2017 елның I кварталына торак урынының гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача бәясе турында» 2017 елның 22 декабрендәге 1003 номерлы боерыгына туры китереп, шулай ук Торак кодексының 49, 51 статьяларына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2017 елның беренче кварталына гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләме:

1.1.1.ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 157 607 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен - 1 473 318 сум;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен - 1 894 266 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен - 2 525 688 сум;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен - 3 157 110 сум;

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен - 3 788 532 сум;

1.1.7.җиде кешедән торган гаилә өчен - 4 419 954 сум;

1.2. һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен - 12 591,44 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен - 8012,74 сум;

1.2.3.өч кешедән һәм  аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен  - 6868, 06 сум.

2. «ЗМР Торак сәясәте департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлегенә, торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда, әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән иң чик күрсәткечләрне кулланырга.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм  Интернет челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче | А.Х. Сәхибуллин

**2017 елның I кварталына гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләмен билгеләү**

**МЕТОДИКАСЫ**

1. **Базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече**

**СЖ= НП*РС* РЦ, биредә**

СЖ-базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яки мөлкәт хакының иң чик күрсәткече;

НП – гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС-гаилә әгъзалары саны;

РЦ - РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан раслана торган 1 кв.м. мәйданның уртача исәп -хисап базар бәясе (2017 елның беренче кварталына - 35 079 сум)

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ= 35 079 *33= 1 157 607

б) ике кешедән торган гаиләгә:

СЖ=35 079 *42= 1 473 318

в) өч кешедән торган гаиләгә:

СЖ=35 079 *18*3= 1 894 266

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

СЖ=35 079 *18*4= 2 525 688

д) биш кешедән торган гаиләгә:

СЖ=35 079 *18*5= 3 157 110

ж) алты кешедән торган гаиләгә:

СЖ=35 079 *18*6= 3 788 532

з) җиде кешедән торган гаиләгә:

СЖ=35 079 *18 *7= 4 419 954

2. **Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме**

**ПД=0,7*СЖ*ПС/ {1-[(1+ПС) - КП]}/ (0,3*РС), биредә**

СЖ-социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

ПС - кредит буенча бер айга процент ставкасы (14/12);

КП -бөтен кредит срогына кредит буенча түләүләрнең гомуми саны ( айлар саны);

РС-гаилә әгъзалары саны;

0,7-кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,3 — кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кеременә карата нисбәте;

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

ПД=(0,7*1 157 607*1,16) / {1-[(1+1,16) - 250]}/ (0,3*1)= 12 591,44

б) ике кешедән торган гаиләгә:

ПД=(0,7*1 473 318*1,16) / {1-[(1+1,16) - 250]}/ (0,3*2) = 8012,74

в) өч кешедән һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә:

ПД=(0,7*1 894 266*1,16)/ {1-[(1+1,16) - 250]}/ (0,3*3)= 6868, 06

г) дүрт кешедән һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә:

ПД=(0,7*2 525 688*1,16)/ {1-[(1+1,16) - 250]}/ (0,3*4)= 6868,06

« ЗМР торак сәясәте департамент»МКУ
җитәкчесе Ж.Е. Багабиева

»